Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең
Түбән Ушма авылында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«13» ноябрь, 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларыы турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23.1 статьясы нигезендә Балтач муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлегендә гражданнар җыены карар итте:

1. 2023 елда Балтач районы Кече Лызи авыл җирлегенең Түбән Ушма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булганнарга 400 сум күләмендә үзара салым кертергә, үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән: 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән, сәләтсез гражданнардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, өлкән яшьтәге ялгыз пенсионерлардан, үз – үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнардан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче тулы булмаган куп балалы гаилә әгъзаларыннан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Гагарин урамындагы юлларны норматив хәлгә китерү,
- Кече Лызи авылында һәлак булган сугышчыларга һәйкәлне ремонтлау.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов